Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Түбән Кама милли паркы» ФДБУ территориясендә урнашкан объектларга керү максатларында кадастр номеры 16:39:0000:735 булган җир кишәрлегенә гомуми файдаланудагы җирләрне (юлларны) билгеләү өлешендә проектны карау буенча халык тыңлаулары беркетмәсе

Үткәрү датасы һәм вакыты: 08 август 2022 ел 15:00
Үткәрү урыны: Кече Шилнә авыл җирлеге, Олы Шилнә авылы, Киров ур., 55 йорт.

Катнашучылар:
1. Нәдершин А.Н. – Тукай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;
2. Попова Е.В. – Тукай муниципаль районы юридик бүлеге баш белгече;
3. Даутов А.Г. – Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе;
4. Кече Шилнә авыл җирлегендә яшәүчеләр – 7 кеше.
Барлыгы: 10 кеше.

Нәдершин А.Н.: «Хәерле көн! Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 4 июлендәге 54 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Түбән Кама милли паркы» ФДБУ территориясендә урнашкан объектларга керү максатларында кадастр номеры 16:39:0000:735 булган җир кишәрлегенә гомуми файдаланудагы җирләрне (юлларны) билгеләү өлешендә проектны карау буенча халык тыңлаулары үткәрелә».

Чыгыш ясады Нәдершин А.Н.: «16:39:00000:735, 16:39:000000:577, 16:39:101601:2586, 16:39:102101:322 кадастр номерлы җир кишәрлекләре аша Белоус, Ильичевка, Опушка, Алан торак пунктлары, Первомайка микрорайоны, «Горизонт», «Сосновый Бор», «Весна-2», «Бриз», «Прибрежный», «Бриз-2», «Орбита-2» бакчачылык коммерциясез ширкәтләре, ял базалары һәм пионер лагерьларына керү юлларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау зарурлыгына бәйле рәвештә 16:39:000000:735 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзергә кирәк».

Нәдершин А.Н.: «Тәкъдим ителгән тема буенча фикер алышуыгызны сорыйм».

Нәдершин А.Н.: «Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр юк».

Нәдершин А.Н.: «Әгәр каршылыклар һәм башка фикерләр булмаса, халык тыңлаулары ябылган дип санала».
Карар бирделәр: Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Түбән Кама милли паркы» ФДБУ территориясендә урнашкан объектларга керү максатларында кадастр номеры 16:39:0000:735 булган җир кишәрлегенә гомуми файдаланудагы җирләрне (юлларны) билгеләү өлешендә проектны эш тәртибендә расларга тәкъдим итәргә.

Тукай муниципаль районы
Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А. Н. Нәдершин